# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

**№ 1** **12.11.2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Мәлбагыш авыл җирлеге составына керүче
Түбән якый авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 12 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

«Сез 2020 Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Түбән Якый авылының 1 Май урамына юлларга таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш төяү)
- Түбән Якый авылында юлларны кардан чистарту;
- Түбән Якый авылында җәйге вакытта үлән чаптыру, территорияне җыештыру хезмәтләре;
- бүләк, сувенир продукциясе сатып алу, «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Халыкара инвалидлар көне», «Яңа ел», «Җиңү Көне " бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү;»

« РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 206 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны - 148 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашучы 148 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге составына керүче Түбән Якый авылыдна узган халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: «Сез 2020 Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум

күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Түбән Якый авылының 1 Май урамына юлларга таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш төяү)

- Түбән Якый авылында юлларны кардан чистарту;

- Түбән Якый авылында җәйге вакытта үлән чаптыру, территорияне җыештыру хезмәтләре;

- бүләк, сувенир продукциясе сатып алу, «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Халыкара инвалидлар көне», «Яңа ел», «Җиңү Көне " бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү;»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

-Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Түбән Якый авылы, Кашапов урамы, 23 йорт.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мәлбагыш авыл җирлеге Башлыгы И.Ә.Әхтәмова